Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Нырья авыл җирлеге Советы

КАРАР

2022 елның 24 ноябре № 36

«Җир салымы турында» 2013 елның 23 ноябрьдәге 29 номерлы Нырья авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Нырья авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 23 ноябрьдәге 29 номерлы Нырья авыл җирлеге Советы карарына ( 2014 елның 24 ноябрьдәге 32 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 25 ноябрьдәге 13 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 07 ноябрьдәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрьдәге 30 номерлы, 2018 елның 20 декабрьдә 33 номерлы, 2019 елның 28 ноябрьдәге 20 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварда 1 номерлы, 2020 елның 20 ноябрьдәге 9 номерлы Нырья авыл җирлеге Советы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пункт. түбәндәге эчтәлекле «5», «6» пунктчаларын өстәргә:

«5) Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

6) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.»

2. «Җир салымы турында» 2013 елның 23 ноябрьдәге 29 номерлы Нырья авыл җирлеге Советы карарының 3 пунктындагы «5», «6» пунктчалары нигезләмәләренең (әлеге карар редакциясендә) гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Нырья авыл җирлеге башкарма комитетына «Җир салымы турында» 2013 елның 23 ноябрьдәге 29 номерлы Нырья авыл җирлеге Советы карарының 3 пунктның «5», «6» пунктчаларында (әлеге карар редакциясендә) күрсәтелгән гражданнар исемлеген формалаштырырга һәм салым органына тапшырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы В.В.Васильев

ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336